**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 14 август № 591

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2010 ел, 24 август, 678 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2010 ел, 24 август, 678 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 8 октябрь, 790 нчы, 2010 ел, 3 декабрь, 987 нче, 2010 ел, 30 декабрь, 1175 нче, 2011 ел, 28 апрель, 347 нче, 2011 ел, 30 апрель, 356 нчы, 2011 ел, 25 июнь, 576 нчы, 2011 ел, 19 август, 688 нче, 2011 ел, 19 сентябрь, 778 нчы, 2012 ел, 20 гыйнвар, 31 нче, 2012 ел, 25 апрель, 323 нче, 2012 ел, 1 июнь, 464 нче, 2012 ел, 31 октябрь, 932 нче, 2012 ел, 31 декабрь, 1186 нчы, 2013 ел, 30 гыйнвар, 50 нче, 2013 ел, 29 апрель, 298 нче, 2013 ел, 29 июнь, 457 нче, 2013 ел, 26 август, 600 нче, 2013 ел, 26 октябрь, 796 нчы, 2013 ел, 31 декабрь, 1105 нче, 2014 ел, 27 июнь, 443 нче, 2014 ел, 29 октябрь, 791 нче, 2015 ел, 20 февраль, 104 нче, 2015 ел, 10 март, 140 нчы, 2015 ел, 8 апрель, 230 нчы, 2015 ел, 16 май, 350 нче карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

2.6 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6. Яшьләр сәясәте учреждениеләренең һәм «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының Физик культура һәм яшүсмерләр спорты республика үзәге» дәүләт учреждениесенең мәгариф тармагы хезмәткәренең төп оклады түбәндәге формула буенча исәпләнә:»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре

һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

2.5 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5. Яшьләр сәясәте учреждениеләренең һәм «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының Физик культура һәм яшүсмерләр спорты республика үзәге» дәүләт учреждениесенең мәгариф тармагы хезмәткәренең төп оклады түбәндәге формула буенча исәпләнә:»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт оешмаларының физик культура һәм спорт хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керүче хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

2.5 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5. Яшьләр сәясәте учреждениеләренең һәм «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының Физик культура һәм яшүсмерләр спорты республика үзәге» дәүләт учреждениесенең мәгариф тармагы хезмәткәренең төп оклады түбәндәге формула буенча исәпләнә:»;

5 бүлектә:

3 таблицага түбәндәге эчтәлекле 74 – 75 юллар өстәргә:

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «74 | Биатлон | 1,5 | 2,2 | 3,3 | 3,7 | 5,6 | 6,5 | 8,9 | 12,5 | 17 | 23 | 35 |
| 75 | Фристайл | 1,5 | 2,2 | 3,2 | 4,6 | 5,6 | 8,3 | 12,5 | 15,9 | 20 | 30 | 40»; |

4 таблицага түбәндәге эчтәлекле 74 – 75 юллар өстәргә:

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «74 | Биатлон | 4 | 6 | 9 | 10 | 12 | 14 | 16 | 18 | 24 | 28 | 32 |
| 75 | Фристайл | 4 | 6 | 8 | 10 | 12 | 15 | 18 | 20 | 24 | 24 | 32»; |

5 таблицага түбәндәге эчтәлекле 74 – 75 юллар өстәргә:

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «74 | Биатлон | 15 | 15 | 15 | 15 | 12 | 12 | 10 | 8 | 2 | 2 | 1 |
| 75 | Фристайл | 15 | 15 | 14 | 12 | 12 | 10 | 8 | 7 | 6 | 5 | 4»; |

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренең медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керүче хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

2.5 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5. Яшьләр сәясәте учреждениеләренең һәм «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының Физик культура һәм яшүсмерләр спорты республика үзәге» дәүләт учреждениесенең мәгариф тармагы хезмәткәренең төп оклады түбәндәге формула буенча исәпләнә:».

2. Бу карарның гамәле 2015 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков